РЕШЕНИЕ

от 26 марта 2021 г. № 1

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахитов авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2020 елның 01 декабрендәге 1 номерлы Вахитов торак пункты җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахитов авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 26 мартында түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахитов авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2020 елның 01 декабрендәге 1 номерлы Вахитов торак пункты җыены карарына түбәндәге эчтәлекле 2 нче абзацны өстәү юлы белән үзгәрешләр кертергә сез ризамы:

«- Әфганстанда булган сугышчы-интернационалистларга һәйкәл төзү, мемориаль такта; проект-смета документларын төзү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү;»

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 639 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 340 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 333 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 7 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахитов авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2020 елның 01 декабрендәге 1 номерлы Вахитов торак пункты җыены карарына түбәндәге эчтәлекле 2 нче абзацны өстәү юлы белән үзгәрешләр кертергә сез ризамы:

«- Әфганстанда булган сугышчы-интернационалистларга һәйкәл төзү, мемориаль такта; проект-смета документларын төзү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү;»

«РИЗА» «КАРШЫ».

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Янил авыл җирлеге башлыгы: И.Х.Корбанов

ОГРН 1021607753310
ИНН 1623001893